| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА КУРНАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>КӨРНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Коры Көрнәле ав. **КАРАР**

**02.12.2021** **№ 3**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Көрнәле авыл җирлегенең Коры Көрнәле
авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге Уставының нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап 2021 елның 15 декабренә график нигезендә билгеләргә (Кушымта).

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Көрнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

-кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пунктта урамнарны яктырту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункттагы юлларны төзекләндерү (юлларга вак таш җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру һәм контейнерлар сатып алу (төзелеш материалы сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- су башнясы өчен су насослары алу;

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Көрнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге башлыгы** **Д.Б.Казакова**

Кушымта

ГРАФИК
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегендә Коры Көрнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап үткәрү

| № п/п | Үткәрү датасы | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 15.12.2021 | 9:00 сәг. | Коры Көрнәле мәдәният йорты бинасы | М.Җәлил Фәрид Шәйдуллин Мәктәп Көнчыгыш Яр буе Көнбатыш Зәки Кутлин урамнары |
| 2 | 15.12.2021 | 10:30 сәг. | Коры Көрнәле мәдәният йорты бинасы | Ибатуллин, Хабибулла Хәйруллин урамнары |
| 3 | 15.12.2021 | 13:15 сәг. | Коры Көрнәле мәдәният йорты бинасы | Хади Такташ, Татарстан урамнары |